КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 июль г.Казань № 665

Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин